ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 603 31 июль,2018ел

# Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Расларга:
1) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә
сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне, 1нче кушымта нигезендә;
2) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә
сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыруга хокук бирүче электрон аукционны үткәрү һәм оештыру нигезләмәсен, 2нче кушымта нигезендә.

2. Вәкаләтле орган итеп билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә
сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыруга хокук бирүче электрон аукционны үткәрү һәм оештыру буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль заказ урнаштыру бүлеген;

2)сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыруга хокук бирүдә килешүләр төзү эшен оештыру буенча һәм аларны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» казна учреждениесен.
3. Әлеге карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләр өчен гамәлдә.
4. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эш бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.И.Беляевка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов